ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» июль 2023ел № 202

«2022 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2022 елның 298 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының «Электр энергетикасы һәм энергияне сак тоту өлкәсендә федераль законнарны бозуларны бетерү турында» 10.05.2023 елның 02-08-02/206 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2022 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2022 елның 298 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының
__20. 07.__2023 елның __202__номерлы
карары белән расланды

«2022 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2022 елның 298 номерлы карарына үзгәрешләр

«2022 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2022 елның 298 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «2022 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасында:

1.1. «Төп программа чаралары исемлеге» программасының 1 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«-энергетика ресурсларын тапшыру өчен кулланыла торган күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын ачыклау, мондый объектларны күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектлары буларак исәпкә алуны оештыру һәм алга таба муниципаль милек хокукын күчемсез мөлкәтнең мондый хуҗасыз объектларына тану буенча;

- энергетика ресурсларын тапшыру өчен файдаланыла торган хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары белән идарә итүне оештыру буенча мондый объектлар ачыкланган вакыттан алып, шул исәптән аларны эксплуатацияләгәндә барлыкка килә торган энергетика ресурсларының (җылылык энергиясен, электр энергиясен кертеп) норматив югалтуларын компенсацияләү чыганагын билгеләү, аерым алганда, мондый объектлар белән идарә итүче оешма тарифына күрсәтелгән югалтуларны компенсацияләү чыгымнарын Россия Федерациясе законнары нигезендә кертү хисабына;

- икенчелге энергия ресурсларын һәм (яки) яңартыла торган энергия чыганакларын энергия чыганаклары буларак куллану очраклары санын арттыру буенча.».

1.2. «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» программасы паспортының 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәлергә:

«Финанслау чыганаклары:

- энергия ресурслары нәтиҗәлелеге чараларын һәм программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның үз һәм заем акчалары:

- Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән бюджеттан тыш чыганакларыннан акчалар.

Финанслау күләмнәре:

2022 ел - 49836,5 млн. сум

2023 ел - 51491,8 млн. сум
2024 ел - 56126,6 млн. сум
2025 ел - 60857,4 млн. сум
2026 ел - 66744,8 млн. сум
2027 ел - 73084,2 млн. сум.»

1.3. «Коммуналь инфраструктура системаларының энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары» программасының 10.2 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-икенчел энергетика ресурсларын һәм (яисә) торгызыла торган энергия чыганакларын энергия чыганаклары буларак куллану очракларының санын арттыру буенча».